ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево, 422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БОРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы, 422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

14.11.2019 с. Татарское Бурнашево 4

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 30 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 30 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә.

   1 этап: Татар Борнашы авылы, Первомайская, Октябрьская урамнары халкы

   2 этап: Татар Борнашы авылы, Советская, Школьная, Новая, Молодежная, Луговая, Дубравная урамнары халкы.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Татар Бурнашы авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризалыгыгыз бармы?:

**- Татар Борнашы авылында вак таш җәелгән юлларны ремонтлау һәм вак таш җәяү**

« ӘЙЕ» «ЮК»

5. Гражданнар җыеннарын уздырырга:

   1 этап: Татар Борнашы авылы, Первомайская урамы буенча 48нче номерлы йорт янында

2 этап: Татар Борнашы авылы, Советская  урамы буенча 58нче номерлы йорт янында

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

**Югары Ослан муниципаль районының**
**Борнаш  авыл җирлеге Башлыгы С.В.Бурукин**